КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 4 ноябрь г.Казань № 1049

2021 – 2022 елларда Татарстан Республикасы сәнәгать предприятиеләренең цифрлы өлгереше дәрәҗәсен арттыру буенча чаралар турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы икътисады, социаль өлкәсе һәм дәүләт идарәсе тармакларын цифрлы трансформацияләү өлкәсендәге стратегияне раслау турында» 2021 ел, 18 август, 748 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы икътисады, социаль өлкәсе һәм дәүләт идарәсе тармакларын цифрлы трансформацияләү өлкәсендәге стратегияне гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына, Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы белән берлектә:

Татарстан Республикасы сәнәгать предприятиеләрен цифрлаштыру дәрәҗәсен мониторинглауны дәвам итәргә;

Татарстан Республикасы сәнәгать предприятиеләре өчен цифрлы трансформацияләү стратегиясен эшләү һәм раслау мәсьәләләре буенча уку-укыту семинарын, шулай ук Татарстан Республикасы сәнәгать предприятиеләрендә төп класслар буенча инженерлык программа тәэминатын һәм цифрлы платформаларны гамәлгә кертү буенча дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары буенча семинар үткәрергә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе белән берлектә, 2021 елның 30 декабренә кадәр Татарстан Республикасы сәнәгать предприятиеләре җитәкчеләре һәм аларның цифрлы трансформацияләү өчен

җаваплы урынбасарлары өчен цифрлы трансформацияләү юнәлешләре буенча уку-укыту программалары буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тәкъдимнәр кертергә, шулай ук Татарстан Республикасының Цифрлы нигездә үстерүгә ярдәм күрсәтү ассоциациясенә әлеге тәкъдимнәрне кертүне тәкъдим итәргә.

3. Югары белем бирүче «Иннополис университеты» коммерциягә карамаган автоном оешмасына, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән берлектә, 2021 елның 30 декабренә кадәр югары белем бирүче «Иннополис университеты» коммерциягә карамаган автоном оешмасы базасында демонстрацияләү мәйданчыклары булган 4.0 Индустрия компетенцияләре үзәген оештыру буенча һәм 2025 елга кадәр кирәкле финанслау күләме турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тәкъдимнәр кертергә.

4. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына, Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы белән берлектә, түбәндәгеләрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә:

2022 елның 30 гыйнварына кадәр Татарстан Республикасы сәнәгать предприятиеләрендә әйберләрнең сәнәгать интернетын гамәлгә кертү буенча тәкъдимнәрне;

2022 елның 30 гыйнварына кадәр Татарстан Республикасы сәнәгать предприятиеләре тарафыннан гамәлгә кертелгән цифрлы чишелешләр каталогын булдыру буенча тәкъдимнәрне, шулай ук Татарстан Республикасы сәнәгать предприятиеләрендә төп класслар буенча Россия инженерлык программа тәэминатын һәм цифрлы платформаларны (CAD/CAE/CAM/PLM/MES/PDM/MDM һ.б.) эшләүгә һәм гамәлгә кертүгә ярдәм күрсәтү чаралары буенча тәкъдимнәрне.

5. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына, Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы белән берлектә, 2022 елның 1 мартына кадәр мәҗбүри табигый сынауларны виртуаль сынаулар белән алыштыру мөмкинлеген һәм кабат үткәрелә торган сынаулар санын киметүне күздә тота торган норматив хокукый актларга үзгәрешләр кертү буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тәкъдимнәр кертергә.

6. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең һөнәри белем бирүче мәгариф оешмаларын гамәлгә куючылары булган башкарма органнарына, эш бирүчеләр ихтыяҗына карап, белгечләр әзерләү, мәгариф программаларына төзәтмәләр кертү, Татарстан Республикасы сәнәгать предприятиеләрендә җитештерү практикаларын оештыру буенча уртак эш оештыру өчен әлеге мәгариф оешмаларының идарә органнарына Татарстан Республикасы сәнәгать предприятиеләре вәкилләрен кертү эшен башкарырга.

7. Татарстан Республикасы сәнәгать предприятиеләренә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

2021 елның 15 декабренә кадәр оешма җитәкчесе урынбасарлары арасыннан цифрлы трансформацияләү (CDTO) өчен җаваплы затларны билгеләүне;

2021 елның 25 декабренә кадәр гамәлгә куючылар (директорлар советлары) тарафыннан цифрлы трансформацияләү стратегиясен эшләүне һәм раслауны, әлеге стратегия чараларын үтәүгә финанслау лимитларын билгеләүне, шулай ук персоналга сакчыл җитештерү инструментларына һәм цифрлы трансформацияләү нигезләренә

өйрәтүне оештыру чаралары планын эшләүне, шул ук вакытта цифрлы трансформацияләү һәм цифрлы технологияләрне гамәлгә кертү өлкәсендә хезмәткәрләрнең компетенциясен даими рәвештә күтәрүне һәм персоналга цифрлы трансформацияләү чараларын һәм проектларын тормышка ашыруга стимул бирү механизмнарын булдыруны тәэмин итүне;

2022 елның 30 гыйнварына кадәр Татарстан Республикасы сәнәгать предприятиеләренең цифрлы чишелешләре каталогын булдыру өчен цифрлы чишелешләрне гамәлгә кертү турында Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына мәгълүмат бирүне, шулай ук яңа продукция үрнәкләренең виртуаль сынауларга алыштырыла алган мәҗбүри табигый сынаулар исемлеге буенча Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына тәкъдимнәр җибәрүне;

әйбернең проектын ясау һәм, алга таба аның масштаблыгын артырып, киләсе тормыш циклы этаплары өчен кирәкле мәгълүмат-ларны тәэмин итә торган җитештерүләрнең цифрлы игезәкләрен охшаш җитештерүләр өчен булдыруны тәэмин итүне.

8. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры А.Ә.Кәримовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин